ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 08 » сентябрь 2021 ел** **№ 682**

**«2021 - 2023 елларга Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

«Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте Стратегиясе, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү, үстерү һәм аларның функциональлеген арттыру, шулай ук республикадан читтә татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү максатыннан, Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2021 - 2023 елларга Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын (алга таба - Программа) расларга.

2. «2021-2023 елларга Арча муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча чаралар программасы чараларын раслау турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 21 маендагы 346 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасына ел саен чираттагы финанс елына район бюджетын формалаштырганда, әлеге

максатларга Арча муниципаль районы бюджетыннан җибәрелә торган акчалар чикләрендә, мөмкинлекләрне исәпкә алып, Программа чараларын үтәү өчен акча бүлеп бирүне күздә тотарга.

4. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының Программаны үтәүдә катнашучы структур бүлекчәләренә күздә тотылган чараларның үз вакытында үтәлешен тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Мөхәрәмов

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
"08" сентябрь 2021 ел, №682
карары белән расланды

**«2021-2023 елларга Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасы**

**Муниципаль программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| 1.Муниципаль программаның исеме | «2021-2023 елларга Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» (алга таба - Программа) |
| 2. Муниципаль программаны эшләү өчен нигез | Программа Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Федераль закон, 2005 елның 1 июнендәге 53-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе дәүләт теле турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте Стратегиясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы законы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары |

| | |
|---|---|
| | белән расланган 2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелгән эшне дәвам итәргә тиеш. |
| 3.Муниципаль программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты |
| 4.Муниципаль программаның төп максаты | Татарстан Республикасында татар, рус һәм башка телләрне, шулай ук Татарстан Республикасыннан читтә татар телен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру |
| 5.Муниципаль программаның төп бурычлары | Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру; Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең оптималь кулланылышын тәэмин итү; «Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм башка телләр турында» Законны эзлекле гамәлгә ашыру. |
| 6.Муниципаль программаның төп чараларын үтәүчеләр | ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МУ,<br>ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәдәният идарәсе" МУ,<br>ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 7.Муниципаль программаны үтәү сроклары һәм этаплары | 2021 - 2023 еллар |
| Муниципаль программа максатларына ирешү индикаторлары | 2022 елга:<br>Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны һәм Программаныү тәү мәсьәләләре йөкләнгән муниципаль берәмлек органнары һәм җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре саны 4 берәмлеккә җиткереләчәк;<br>Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге аудиовизуаль мәгълүматның муниципаль идарә, инфокоммуникация өлкәсендә һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә чагыштырмасы |

| | |
|---|---|
| | 50%/50% ка җитәчәк;<br>мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында татар милләтеннән булган балаларны туган татар телендә укыту һәм тәрбияләү өлеше 85,6 процент булып калачак;<br>гомуми белем бирү оешмаларында татар милләте балаларын туган телдә укыту 52,24 процентка җитәчәк;<br>гомуми белем бирү оешмаларында рус милләтендәге балаларны туган телдә укыту өлеше 100 процент дәрәҗәсендә сакланачак;<br>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында массакүләм мәгълүмат чараларының өлеше артачак:<br>татар телендә-30 процент;<br>Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе халыклары телләрендәге һәркем файдалана алырлык китапханәләрнең җыелма фонды, рус теленнән тыш, 25 процентка җитәчәк;<br>Программаны үтәү барышында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында тел мәсьәләсе турында массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылган мәкаләләр саны 10 берәмлеккә җитәчәк;<br>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында этнотел вәзгыяте үсешен һәм Программаны үтәү нәтиҗәлелеген тикшерүләр саны 3 берәмлеккә җитәчәк. |
| 9.Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау күләме республика һәм Арча муниципаль районы бюджеты хисабына 165,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2021 ел – 45,0 мең сум<br>2022 ел – 60,0 мең сум<br>2023 ел– 60,0 мең сум |

## 1 нче бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ ПРОБЛЕМАНЫ ТАСВИРЛАУ

Муниципаль программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманы тасвирлау һәм программаның максатлары

Программа Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясе дәүләт теле турында» 2005 елның 01 июнендәге 53-ФЗ номерлы, «Россия

Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Федераль законнар, «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XIII номерлы, «Татарстан Республикасында татар телен дәүләт теле буларак куллану турында» 2012 елның 12 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру буенча алга таба чаралар хакында» Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2008 елның 27 июнендәге 451 номерлы карары нигезендә эшләнде.

Әлеге Программа Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен оптималь шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасында 173тән артык милләт халкы яши. 8 милләт вәкилләренең саны 4 меңнән артык кеше тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында 51291 кеше яши, шуларның 92,8% ы татарлар, 5,9% ы руслар, 0,5% ы марилар.

Телләр үсешенә мәгълүмати киңлек зур йогынты ясый. Соңгы вакытта телләрнең сүз байлыгы кимү, орфография, пунктуация һәм стилистика хаталары арту күзәтелә, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында да. Яшьләр теле чит ил алынмаларына, жаргоннар, вульгар сүзләр һәм компьютер лексикасына бай. Иҗтимагый оешмаларның актив катнашында дәүләт, ведомство һәм муниципаль хакимиятнең барлык дәрәҗәләрендә телләрне саклау механизмын эшләү зарур.

Әлеге юнәлештә әйдәп баручы рольне мәгариф оешмалары уйный. Аерым алганда, Арча муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә ике туган тел: рус, татар телләрен өйрәнәләр. Укыту методикасын камилләштерү мөһим бурыч булып тора.

Туган телен белгән татарлар саны азаю тенденциясе саклана, татар телен куллану кимү күзәтелә, шул исәптән көндәлек эштә һәм көнкүрештә дә. Бу күренешләр татар телендә белем бирүче мәктәпләрнең саны кимү, туган телдә белем бирү системасының тулы канлы эшчәнлеге өчен сәяси-хокукый һәм институциональ мөмкинлекләр югалу белән бәйле. Халыкның туган телне һәм этник мәдәниятне югалту куркынычы татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау, үстерү һәм тарату проблемасының актуальлеген көчәйтә.

Гамәлдәге законнар район халкының мәдәни-тел хокукларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга нигез салды.

Законнарны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасында дәүләт телләрен өйрәнү һәм туган телдә белем бирүне үстерү һәм Арча муниципаль районында татар телендә белем бирүче мәктәпләрнең санын саклап калуга юнәлдерелгән.

Гомумән алганда, Арча муниципаль районы уку йортлары татар телен һәм әдәбиятын укытуны оештыру буенча квалификацияле кадрлар һәм укыту-методик әдәбият белән тәэмин ителгән. Милли мәгарифне үстерүгә ярдәм итү максатыннан, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен өйрәнү буенча методик кабинетларның укыту-матди базасын заманча җиһазлар, иллюстратив материаллар һәм күрсәтмә әсбаплар белән җиһазлау эше башкарылды. Интерактив белем бирү һәм телләр өйрәтүнең мультимедиа контентын системалы эшләү һәм гамәлгә кертү башланды.

Халыкны туган телдәге әдәбият белән тәэмин итү максатыннан, шәһәр һәм авыл китапханәләре фондлары ел саен Татарстан Республикасында яшәүче халыклар телләрендәге әдәбият белән тулылана. Нәшрият эшчәнлеге әлеге телләрдә башкарыла.

Алдагы программа нәтиҗәләренә анализ ясау шуны күрсәтә: Арча муниципаль районында телләрне саклау һәм үстерү өлкәсендә куелган тырышлыкларга карамастан, алга куелган максатларның барысына да ирешелмәде (тоткарлаучы факторлар аркасында). Сәбәпләре:

а) алдагы программа тиешенчә финансланмау;

б) районда яшәүче халыкларның татар телен, милли телләрне өйрәнү мотивациясенең начар булуы, рус телен һәм сөйләм культурасын саклау һәм үстерү буенча чараларның җитәрлек булмавы;

в) «мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми һәм урта һөнәри белем» схемасы буенча туган телдә өзлексез белем бирүнең тулы бер системасы булмау;

г) мәгълүмати-коммуникатив киңлектә тиешле нормалар, стандартлар һәм технологияләр нигезендә татар теленең кулланылышын тәэмин итүдә комплектлылык һәм системалылык җитәрлек дәрәҗәдә булмау;

Әлеге Программа алдагы программаны тормышка ашыру тәҗрибәсен анализлау, проблеманың барлык өлкәләрен һәм аспектларын колачлауны, кабул ителә торган чараларның нәтиҗәлелеге һәм телләрнең тормышка сәләтлелегенә бәйле барлык төп факторларга йогынтысын тәэмин итүгә юнәлдерелгән яңа төп принципларны куллану нигезендә эшләнде.

| Проблеманың исеме | Аның барлыкка килү сәбәпләрен анализлау, максатчанлыгын нигезләү һәм аны муниципаль дәрәҗәдә хәл итү зарурилыгы | Муниципаль программаның максатлары исеме | Әлеге муниципаль программа ирешүгә ярдәм итә торган муниципаль заказчы бурычының исеме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Телләрнең лексик күләме кимү, орфография, | Телләр үсешенә мәгълүмати киңлек зур йогынты ясый. Яшьләр теле чит ил | -Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак татар һәм | Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне |

| | | | |
|---|---|---|---|
| пунктуация һәм стилистика хаталары арту тенденциясе | алынмалары, жаргоннар, вульгар сүзләр һәм компьютер лексикасы белән алыштырылган. | рус телләренең тигез яшәешенә ярдәм итү; -татар һәм рус телләренең бербөтен системасын һәм татар һәм рус телләрендә укытуны үстерү | саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру; Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең оптималь эшләвен тәэмин итү; «Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм башка телләр турында» Законны эзлекле гамәлгә ашыру. |
| Районда яшәүче халыкларның милли телләрне үзләштерү мотивациясенең кимүе | Телләрне саклау һәм үстерү эшендә башкарыла торган тырышлыкка карамастан, хәл ителмәгән проблемалар да бар: Татар телен, районда яшәүче халыкларның милли телләрен үзләштерүгә кызыксынуның кимүе. Әлеге проблеманың сәбәпләре: мәгълүмат киңлегенең милли тел үсешенә тискәре йогынтысы | -Татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларын фәнни һәм фәнни-методик ярдәм күрсәтү; -Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында яшәүче халыклар вәкилләренең телләрен саклау һәм үстерү | Милли белем һәм тәрбия, туган (татар) татар телен тормышның барлык өлкәләрендә куллануны киңәйтү |

Республиканың милли байлыгы буларак, Татарстан Республикасы дәүләт телләре дәүләт тарафыннан саклана һәм хуплана. Дәүләт сәясәтенең состав өлешләреннән берсе буларак, тел сәясәтенең максаты:

- Арча муниципаль районында татар, рус һәм башка телләрнең тигез хокуклы булуын тәэмин итү.

Программаның төп бурычлары:

1.Татарстан Республикасында тел сәясәтен норматив-хокукый тәэмин итүне камилләштерү;

2.Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең паритет эшчәнлегенә ярдәм итү;

3.Арча муниципаль районында татар һәм рус телләрен өйрәнү һәм татар һәм рус телләрендә укытуның тулы бер системасын үстерү; Татарстан Республикасыннан читтә татар телен укытуга ярдәм итү;

4.Татарстан Республикасында татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларына фәнни һәм фәнни-методик яктан ярдәм итү;

5.Арча муниципаль районында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү;

6. Арча муниципаль районында дәүләт һәм башка телләрне популярлаштыру һәм социаль статусын күтәрү;

7. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында этнотеллелеккә мониторинг үткәрү.

Программаның максаты һәм бурычлары Россия Федерациясе халыкларының мәдәниятләрен һәм телләрен саклау һәм үстерү, аларның рухи бердәмлеген ныгыту, милли азчылыкларның хокукларын тәэмин итү, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның этномәдәни үзенчәлеген саклау, Россия халыкларының гомумдәүләт мәнфәгатьләрен һәм мәнфәгатьләрен берләштерү, чит илләрдә яшәүче ватандашларга ярдәм итү, аларның Россия һәм Татарстан Республикасы белән элемтәләрен үстерүгә ярдәм итү өлешендә Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясенең максатларына һәм бурычларына, шулай ук мәгариф өлкәсендә инновацияләрне стимуллаштыру, талантлы яшьләргә ярдәм итү, иң яхшы укытучыларны һәм укучыларны бүләкләү, заманча белем бирү технологияләрен гамәлгә кертү өлешендә «Мәгариф» өстенлекле милли проекты максатлары һәм бурычларына туры килә.

Татарстан Республикасында рус телен дәүләт теле буларак саклау һәм үстерү чаралары «Россия Федерациясе дәүләт теле турында» 2005 елның 1 июнендәге 53-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программа чаралары түбәндәге программа бурычлары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында телләрне саклау һәм үстерүнең барлык төп аспектларын үз эченә ала:

1 нче бурыч. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында тел сәясәтен норматив хокукый тәэмин итүне камилләштерү.

Әлеге бурычны хәл итү кысаларында тормышка ашырыла торган чаралар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында дәүләт һәм башка телләрне куллану һәм үстерү өлкәсендә хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы норматив хокукый актлар эшләүгә, системалаштыруга, тәрҗемә итүгә юнәлдерелгән.

2 нче бурыч. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында рус һәм татар телләренең дәүләт телләре буларак паритет эшләвенә ярдәм итү.

Әлеге мәсьәләне хәл итү кысаларында тормышка ашырыла торган чаралар түбәндәгеләргә юнәлдерелде:

рус һәм татар телләре өлкәсендә «Ашыгыч лингвистик ярдәм» оештыру;

«Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру инфраструктурасын үстерү;

татар һәм рус телләре буенча тел сертификациясен оештыру;

заманча операцион системалар, гамәли программа пакетлары, электрон җайланмалар һәм технологияләр куллану;

Татарстан Республикасында яшәүче хезмәт мигрантларына рус телен өйрәнүгә ярдәм итү;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районындагы географик объектлар исемнәренең татар һәм рус телләрендәге бердәм каталогын төзү;

социаль аралашу системасында дәүләт телләре буларак рус һәм татар телләре эшчәнлеген укыту-методик тәэмин итү;

Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләрен куллану өчен шартлар тудыру.

3 нче бурыч. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында татар һәм рус телләрен өйрәнү һәм татар һәм рус телләрендә укытуның бөтен системасын үстерү; Татарстан Республикасыннан читтә татар телен укытуга ярдәм итү.

Әлеге мәсьәләне хәл итү кысаларында тормышка ашырыла торган чаралар түбәндәгеләргә юнәлдерелде:

татар һәм рус телләренә өйрәтүне укыту-методик тәэмин итү;

урта һөнәри белем бирү системасында полилингвизм шартларында татар телендә белем бирүне үстерү;

анимацион һәм мультимедиа белем бирү проектларын эшләү;

Россиянең мәдәни белем бирү системасында татар телен үстерүне тәэмин итү;

татар теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары квалификацияле кадрлар әзерләүгә ярдәм итү;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын полилингваль укытуны оештыру;

уңайлы тел һәм мәдәни белем бирү мохите булдыру.

4 нче бурыч. Татарстан Республикасында татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларына фәнни-методик ярдәм күрсәтү:

татар телен куллануда мәгълүмати-коммуникацион технологияләрдән файдалану.

5 нче бурыч. Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү.

Әлеге мәсьәләне хәл итү кысаларында тормышка ашырыла торган чаралар түбәндәгеләргә юнәлдерелде:

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында җәмгыятьтә, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм интернет киңлегендә этнотелгә түземле караш тәрбияләү;

Татарстан Республикасында яшәүче халыклар телләрендәге материаллар тупланган мәгълүмати-ресурс порталы эшендә катнашу;

Мигрантларны адаптацияләү өчен мәдәни-тел ресурсы буларак Татарстан Республикасы дәүләт телләренә өйрәтү;

мәдәни белем һәм тәрбияви тирәлек булдыру.

6 нчы бурыч. Татарстан Республикасында дәүләт һәм башка телләрне популярлаштыру һәм социаль статусын күтәрү.

Әлеге мәсьәләне хәл итү кысаларында тормышка ашырыла торган чаралар түбәндәгеләргә юнәлдерелде:

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау, үстерү һәм популярлаштыру буенча иҗтимагый һәм шәхси инициативаларга грант ярдәме күрсәтү;

мәдәнияттә тел һәм мәдәни мохит булдыру һәм үстерү.

7 нче бурыч. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районындагы этнотел күренешенә һәм Программаны тормышка ашыруның барышына мониторинг ясау.

Әлеге мәсьәләне хәл итү кысаларында башкарыла торган чаралар түбәндәгеләргә юнәлдерелде:

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында этнотел күренешенә социолингвистика мониторингы ясау;

Программаны үтәү барышына мониторинг һәм анализ ясау.

Объектив каршылыклар:

1. Россия Федерациясе законнары үзгәртү. Программадагы хокукый үзгәрешләргә үз вакытында реакция ясау өчен Россия Федерациясе законнарына даими мониторинг үткәрү, Программаның үтәлеше һәм нәтиҗәлелеге механизмы, шулай ук Программага оператив төзәтмәләр кертү мөмкинлеге каралды.

2. Финанс-икътисади шартлар үзгәрү. Проектларның планлаштырылган модуле, финанслау күләменә карап, аларны төрле темпта һәм төрле конфигурациядә тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк.

Төзәтелергә мөмкин каршылыклар:

1. Программаны үтәү белән идарә итүнең начар булуы, кире элемтә булмау. Моны бетерү өчен Программаның нәтиҗәлелеген даими мониторинглау каралган (еллык хисаплардан тыш).

2. Этносоциаль тотрыксызлык һәм этнотелгә түземле караш булмау. Программа чараларын формалаштырганда, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы халкының төрле этнотел төркемнәре мәнфәгатьләре тигезлеген саклау, шулай ук Программада каралган полимәдәни белем бирү проекты этнотелгә түземсез карашны киметергә мөмкинлек бирәчәк. Программада шулай ук җәмгыятьтә этнотелгә толерант мөнәсәбәт пропагандалау буенча чаралар планлаштырылган.

## 2 нче бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ВАКЫТЫ ҺӘМ ЭТАПЛАРЫ

2 нче таблица. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары

| Муниципаль программаны гамәлгә ашыру срогы | Муниципаль программаны гамәлгә ашыру этаплары | Муниципаль программа этапларын гамәлгә ашыру сроклары | Муниципаль программа этабын гамәлгә ашыруның турыдан-туры нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 2021 - 2023 еллар | 2021 ел<br><br>2022 ел<br>2023 ел | 2021 - 2023 еллар | «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасында телләрнең оптималь эшләвен тәэмин итү өчен шартлар тудыру, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәрьяклап үстерүнең һәм таратуның матди-техник, фәнни-тикшеренү, мәгълүмат һәм укыту-методик базасын үстерү |

## 3 нче бүлек. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ТАСВИРЛАУ

3 нче таблица. Муниципаль программаның төп чаралары исемлеге

| № | Чаралар атамасы | Үтәү вакыты | Чараларны башкаручылар | Район бюджеты акчалары исәбеннән финанслау күләме (еллар буенча) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Муниципаль программаны эшләү һәм раслау | 2021 - 2023 еллар | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты | Финанслау таләп ителми |
| 2 | Районда татар һәм рус телләрендә радиотапшырулар чыгару | 2021 - 2023 еллар | «Татмедиа» ААҖенең Арча филиалы | Финанслау таләп ителми |
| 3 | Тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чараларын, шул исәптән сәүдә өлкәсе предприятиеләрендә, Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә рәсмиләштерү | 2021 - 2023 еллар | Район башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары бүлекләре | Финанслау таләп ителми |
| 4 | Урам күрсәткечләрен Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә рәсмиләштерү | 2021 - 2023 еллар | Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге, җирле үзидарә органнары | Финанслау таләп ителми |
| 5 | Милли мәгариф учреждениеләре челтәрен саклау | 2021 - 2023 еллар | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ | Финанслау таләп ителми |
| 6 | Рус телле мәгариф учреждениеләрендә татар сыйныфлары ачуны оештыру | 2021 - 2023 еллар | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ | Финанслау таләп ителми |

<table>
<tr><td>7</td><td>Гомуммәктәп чараларын ТР дәүләт телләрендә оештыру һәм үткәрү</td><td>2021 - 2023 еллар</td><td>«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ</td><td colspan="4">Финанслау таләп ителми</td></tr>
<tr><td colspan="4">Муниципаль программаның максаты<br><br>Арча муниципаль районында, шулай ук Татарстан Республикасыннан читтә (беркетелгән төбәкләрдә) татар, рус һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру:<br>1. Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак рус һәм татар телләренең тигез яшәешенә ярдәм итү;<br>2. Татарстан Республикасында татар һәм рус телләренең бербөтен системасын һәм татар һәм рус телләрендә укытуны үстерү;<br>3. Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү.<br>4. Татарстаннан читтә татар телен саклау һәм үстерү: регионнар белән хезмәттәшлек (Пермь өлкәсе, Мари Иле Республикасы)<br>5. Арча муниципаль районындагы этнотел күренешенә һәм Программаны гамәлгә ашыру барышына мониторинг һәм анализ ясау.</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="4">Ярдәмче программа чаралары</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2" rowspan="3">Халыкара туган телне бәйрәм итүгә багышланган еллык чаралар оештыру һәм үткәрү (21 февраль)</td><td rowspan="3">2021 - 2023 еллар</td><td rowspan="3">Программаны гамәлгә ашыручылар</td><td colspan="4">Муниципаль бюджет</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>2022</td><td>2023</td><td>Барлыгы</td></tr>
<tr><td>-</td><td>15000</td><td>15000</td><td>30000</td></tr>
<tr><td colspan="2">Рус, татар телләрендәге газета</td><td>2021 - 2023</td><td>Программаны гамәлгә</td><td colspan="4">Төп эшчәнлек</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| һәм журналларга язылу | еллар | ашыручылар | |
| Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре өчен татар теле курслары оештыру | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Төп эшчәнлек |
| Татар һәм рус телләрен укытуны укыту-методик яктан тәэмин итү | 2021 - 2023 еллар | Республика бюджеты | Төп эшчәнлек |
| Татар һәм рус телләрен укытуның бербөтен системасын үстерү | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Төп эшчәнлек |
| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны туган телдә укытуны һәм тәрбияләүне тәэмин итү | 2021 - 2023 еллар | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ | Төп эшчәнлек |
| Туган телдә белем һәм тәрбия биреп, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә түгәрәкләр, клублар оештыру | 2021 - 2023 еллар | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ | Төп эшчәнлек |
| Татар телен өйрәнүнең төрле баскычларын тәэмин итә торган «Ана теле» татар телен дистанцион укыту мәгълүмати системасы проектын гамәлгә ашыруда ярдәм итү | 2021 - 2023 еллар | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ | Төп эшчәнлек |
| Татар, рус теле | 2021 - | «Татарстан | Төп эшчәнлек |

<table>
<tr><td>буенча олимпиадалар оештыру һәм үткәрү (мәктәп һәм муниципаль турлар), республика турында катнашуны тәэмин итү</td><td>2023 еллар</td><td>Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ</td><td colspan="4"></td></tr>
<tr><td>Туган телдә иншалар, сәнгатьле уку конкурслары оештыру һәм үткәрү</td><td>2021 - 2023 еллар</td><td>Программаны гамәлгә ашыручылар</td><td colspan="4">Төп эшчәнлек</td></tr>
<tr><td>Татар, рус теле һәм әдәбияты укытучыларының семинар-киңәшмәләрен оештыру һәм үткәрү</td><td>2021 - 2023 еллар</td><td>«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ</td><td colspan="4">Төп эшчәнлек</td></tr>
<tr><td>Республика фәнни-гамәли конференцияләренең, педагогик укуларның муниципаль турларын оештыру һәм үткәрү (К. Насыйри, Ә. Кәлимуллин, Ш. Мәрҗәни, Р.Фәхретдин, Г. Тукай)</td><td>2021 - 2023 еллар</td><td>«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ</td><td colspan="4">Төп эшчәнлек</td></tr>
<tr><td rowspan="3">Татар теле укытучыларының «Осталык дәресләре» Бөтенроссия конкурсының муниципаль турын оештыру һәм уздыру; республика этабында катнашу</td><td rowspan="3">2021 - 2023 еллар</td><td rowspan="3">«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ</td><td colspan="4">Муниципаль бюджет</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>2022</td><td>2023</td><td>барлыгы</td></tr>
<tr><td>5000</td><td>5000</td><td>5000</td><td>15000</td></tr>
<tr><td>Рус, татар теле һәм әдәбияты буенча</td><td>2021 - 2023</td><td>«Татарстан Республикасы</td><td colspan="4">Төп эшчәнлек</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| ДЙА, БРИ, БДИ оештыру һәм үткәрү | еллар | Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ | |
| Күпмәдәниятле белем бирү системасында татар телен үстерүне тәэмин итү | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Төп эшчәнлек |
| Күренекле мәдәният, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре белән очрашулар оештыру | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Төп эшчәнлек |
| Китап күргәзмәләре, әдәби-тематик кичәләр, әңгәмәләр, язучыларның юбилей даталарына күзәтүләр оештыру | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Төп эшчәнлек |
| Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары квалификацияле кадрлар әзерләүгә ярдәм итү | 2021 - 2023 еллар | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ | Төп эшчәнлек |
| Милли гомуми белем бирү учреждениеләренә педагогик кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү | 2021 - 2023 еллар | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ | Төп эшчәнлек |
| Дәүләт телләрен өйрәнү кабинетларының укыту-матди базасын | 2021 - 2023 еллар | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль | Республика бюджеты |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| ныгытуда заманча җиһазлар, иллюстратив материаллар һәм яңа буын күрсәтмә әсбаплары белән ярдәм итү | | районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ | | | | |
| Уңайлы тел һәм мәдәни белем бирү мохите булдыру: «Мин татарча сөйләшәм» республика конкурсының район турын оештыру һәм үткәрү, республика турында катнашу | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Муниципаль бюджет | | | |
| | | | 2021 | 2022 | 2023 | барлыгы |
| | | | 10000 | 10000 | 10000 | 30000 |
| Күпмәдәниятле җәмгыятьтә тел һәм мәдәни мохит булдыру һәм үстерү | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Төп эшчәнлек | | | |
| Милли һәм туган якны өйрәнү әдәбиятында, шул исәптән ТР халыклары телләрендә ел саен үткәрелә торган басмаларда мәктәп китапханәләре фондларын туплау; | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Республика бюджеты | | | |
| Арча муниципаль районында яшәүче халыкларның телләре һәм әдәбияты декадасын үткәрү | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Төп эшчәнлек | | | |
| Туган телләр укытучыларының семинар-киңәшмәләрен оештыру һәм үткәрү | 2021 - 2023 еллар | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы | Төп эшчәнлек | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ | | | |
| Туган телләр укытучыларының квалификациясен күтәрү | 2021 - 2023 еллар | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ | Төп эшчәнлек | | |
| Татар телендә дәреслекләр, методик әсбаплар, аудио- һәм видеоматериаллар, матур әдәбият белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Республика бюджеты | | |
| Фестивальләр, конкурслар үткәрү, укытучылар һәм укучылар төркемнәре белән ике яклы алмашу | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Муниципаль бюджет | | |
| | | | 2021<br>15000 | 2022<br>15000 | 2023<br>15000 |
| Делегацияләр кабул итү, РФ төбәкләре укытучылары һәм укучылары өчен экскурсияләр оештыру | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | 15000 | 15000 | 15000 |
| Семинар-киңәшмәләр, түгәрәк өстәлләр, беркетелгән төбәк вәкилләре белән конференцияләр | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Төп эшчәнлек | | |
| Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру буенча | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Төп эшчәнлек | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| оештыру чаралары | | | |
| Чараларның календарь планнары нигезендә чаралар үтәлешенә анализ | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Төп эшчәнлек |
| Программа чараларын үтәүчеләрнең хисапларына анализ | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Төп эшчәнлек |
| Чараларны үтәүчеләр белән киңәшмәләр үткәрү | 2021 - 2023 еллар | Программаны гамәлгә ашыручылар | Төп эшчәнлек |

## 4 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ҺӘМ АНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программа чараларын үтәү барышында муниципаль заказчы – координатор (Арча муниципаль районы Башкарма комитеты) төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген, чараларны үтәүнең барышын һәм Программаны башкаручыларның акчаларны нәтиҗәле файдалануын контрольдә тота. Программа чаралары дәүләт заказчысы – программа чараларын башкаручылар белән Программа координаторы тарафыннан башкарыла торган муниципаль контрактлар нигезендә тормышка ашырыла.

Программаны үтәүдә катнашучы башкарма комитет бүлекләре, ведомстволар һәм оешмалар Арча муниципаль районы Башкарма комитетына квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр аның үтәлеше турында мәгълүмат тапшыралар.

Программаның нәтиҗәлелеге билгеләнгән срокларда чаралар үтәлеше буенча бәяләнә. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен Татарстан Республикасында этносоциологик тикшеренүләр нәтиҗәләре, шулай ук министрлыкларның һәм ведомстволарның агымдагы хисаплары материаллары, федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы материаллары кулланыла.

Программаны үтәүнең төп нәтиҗәсе-белем дәрәҗәсен, этнотел компетенциясен арттыру, телләр эшчәнлеге өлкәсен киңәйтү, халыкара, милли һәм төбәк дәрәҗәләрендә мәгълүмат алмашу системаларында телләрне куллану мөмкинлекләрен киңәйтү исәбенә фәнни-техник һәм мәдәни үсешне активлаштыру, тел компетенцияләренең, квалификацияләренең, мәгариф, хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын арттыру, мәдәни

һәм этнотел төрлелеген саклау, толерантлыкны һәм милләтара татулыкны үстерү.

Программа Татарстан Республикасының сәяси, икътисади, социаль һәм этномәдәни өлкәләрендә, мәгълүмати киңлектә, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы мәгариф системасында, район һәм республикадан читтә татар телен, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында яшәүче халыкларның телләрен саклап калуны һәм үстерүне чагылдыра торган сан күрсәткечләрен арттыруны, татар һәм рус телләренең социаль статусын һәм абруен күтәрү, аларның функциональ мөмкинлекләрен үстерү өчен нәтиҗәле фәнни эшләнмәләр кертүне күздә тота.

Программада каралган чараларны үтәү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында яшәүче халыкларның телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен популярлаштыручы мәгърифәтчелек чараларының халык өчен үтемле булуына; Татарстан Республикасы дәүләт телләренең функциональлеген арттыруга булышачак; башкаручыларның эшен координацияләү һәм оптимальләштерү, Программаны үтәүнең фәнни һәм эксперт-аналитик базасын көчәйтү өчен тиешле инфраструктура булдырырга ярдәм итәчәк.

Программа социаль һәм мәдәни өлкәләрдә озак сроклы үсеш нәтиҗәләрен тәэмин итә торган механизмнар һәм чаралар системасын булдыруга исәпләнгән. Бу төр нәтиҗәләр гадәти статистик үлчәүләрдә күрсәтелә һәм бәяләүдә чагылдырыла алмый.

Программа чараларын үтәү төрле типтагы һәм дәрәҗәдәге белем бирү оешмаларының белем һәм тәрбия бирү эшчәнлеген үстерергә, педагогның социаль статусын күтәрергә, мәгариф системасын һәм хезмәт күрсәтү өлкәсен этнотел таләпләренә якынайтырга, халыкның туган телне өйрәнүдә һәм үстерүдә конституциячел хокукларын якларга ярдәм итәчәк, Татарстан Республикасы тел законнарын үтәү буенча чараларны координацияләячәк һәм оптимальләштерәчәк.

## 5 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА МАКСАТЛАРЫ ИНДИКАТОРЛАРЫ

Индикаторлар составы турындагы мәгълүмат 4 нче таблицадагы формада китерелә.

4 нче таблица. Муниципаль программа максатлары индикаторлары

| Индикатор атамасы | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч база | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның беренче елы | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның икенче елы | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү (соңгы) |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында татар милләтендәге балаларны туган татар телендә тәрбияләү, белем бирү белән колачлау өлеше, процентлар | % | 100 | 100 | 100 | 100 | |
| Гомуми белем бирү оешмаларында татар милләтендәге балаларны туган татар телендә белем бирү белән колачлау өлеше, процентлар | | 100 | 100 | 100 | 100 | |
| Гомуми белем бирү оешмаларында рус милләтендәге балаларны туган рус телендә укыту белән колачлау өлеше, процентлар | | | | | | |
| Гомуми файдаланудагы китапханәләрнең җыелма фонды өлеше Арча муниципаль | | 100 | 100 | 100 | 100 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| районында тел ситуациясе турында һәм Программаны гамәлгә ашыруның барышы, үткәрелгән чаралар турында массакүләм мәгълүмат чараларында язмалар саны | | | | | |
| Программаны үтәүнең нәтиҗәлелеген анализлау саны | | 1 | 1 | 1 | 1 |

## 6 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫН ҮТӘҮ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ РЕСУРСЛАР

5 нче таблица. муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле ресурслар

| Чыганаклар | Еллар | | | |
|---|---|---|---|---|
| | муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 1 нче елы | муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 2 нче елы | муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 3 нче елы | муниципаль программаны гамәлгә ашыруның барлык еллары |
| Барлыгы,шул исәптән: | | | | |
| Җирле бюджет | 45000 | 60000 | 60000 | 165000 |
| Башка чыганаклар (белешмә өчен) | | | | |

*Тәртипкә 2 нче кушымта*

## МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ҮТӘҮНЕҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛӘРЕ ҺӘМ АНЫ ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

1. Муниципаль заказчы хисап елыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында финанс идарәсенә хисап тапшыра (1 нче кушымта).

2. Муниципаль заказчы хисап елыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр икътисад идарәсенә муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында хисап (2 нче кушымта) тапшыра, анда түбәндәгеләр булырга тиеш:

чынлыкта башкарылган чыгымнарның гомуми күләме, шул исәптән финанслау чыганаклары буенча да;

муниципаль программаның ел дәвамында үтәлгән чаралары исемлеге;

муниципаль программаның ел дәвамында үтәлмәгән чаралары исемлеге;

Программа чараларын үтәүне анализлау, Программа чараларын вакытында тутәмәү һәм финанс чараларын үзләштермәүнең сәбәпләре;

Программаның максатларына ирешкән очракта яисә муниципаль программаны алга таба үтәүне туктатканда, финанслауның өстәмә чыганакларын җәлеп итү, нәтиҗәлелекне арттыру буенча тәкъдимнәр.

Муниципаль программаны үтәүнең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен Программа паспортындагы максатчан индикаторлар һәм күрсәткечләр кулланыла.

*Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә 1 нче кушымта*

_____________________ елга торышы буенча

_______________________________________________________
МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТУРЫНДА ХИСАП
(муниципаль программаның исеме)

мең сум.

| N | Чара | Башкаручы | Финанслау чыганагы | Бюджет ассигнованиеләре күләмнәре 20___елга | Касса чыгымы | Үткәрелгән программа чараларының нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | |
| 2. | | | | | | |
| 3. | | | | | | |
| | БАРЛЫГЫ: | | | | | |
| | | | Федераль бюджеты | | | |
| | | | Республика бюджеты | | | |
| | | | Район бюджеты | | | |
| | | | Бюджеттан тыш чыганаклар | | | |

Район башкарма комитеты структур бүлек җитәкчесе _______________________

(имза) (Ф.И.А.И.)

*Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә 2 нче кушымта*

____________________елга торышы буенча

(муниципаль программаның исеме)

МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ

| | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Муниципаль программаны гамәлгә ашыру башлану вакытына | _____ елга торышы буенча | Муниципаль программаны тормышка ашыру ахырына, планлаштырылган |
| Максатчан бурычлар индикаторлар һәм күрсәткечләр | | | | |
| 1 максат | | | | |
| 1.1 бурыч | | | | |
| Индикатор | | | | |
| Индикатор | | | | |
| ... | | | | |
| 2 максат | | | | |
| 2.1 бурыч | | | | |
| Индикатор | | | | |
| Индикатор | | | | |
| ... | | | | |

ПРОКУРАТУРА РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ПРОКУРАТУРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**ПРОКУРАТУРА
АРСКОГО РАЙОНА**
Гаактионова ул., 1, Арск, 422000
(8-84366) 3 16 80, email: ars.prok@tatar.ru

30.08.2021 № 01-01-2021

На № 2227 от 29.06.2021

Руководителю исполнительного комитета Арского муниципального района Республики Татарстан

Мухарямову Р.Р.

Сообщаю, что прокуратурой Арского района рассмотрен проект муниципальной программы «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан в Арском муниципальном районе на период с 2021 по 2023 годы» (далее – проект Программы).

Содержащиеся в нем нормы достаточны для достижения цели правового регулирования. Правила юридической техники соблюдены. Проект Программы не содержит коррупциогенных факторов. Нарушений требований федерального и республиканского законодательства не выявлено.

Замечаний по рассмотренному проекту НПА не имеется.

Прокурор района

старший советник юстиции Ф.Р. Шайхаттаров

АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
вх. № 015
дата 31 08 20 21

Д.А. Низамов, тел. 32180

Прокуратура Арского района Республики Татарстан